**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.04.2022 г. Казань № 76од

Татарстан Республикасы Мөслим районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннарның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/100 номерлы боерыгы белән расланган исемлегенә үзгәреш кертү турындагы тәкъдимен исәпкә алып, боерам:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннарның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/100

номерлы боерыгы белән расланган исемлегенә, аны яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә әлеге боерыкны «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары М.М. Ибәтовка йөкләргә.

Министр Р.И. Заһидуллин

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/100 номерлы боерыгы белән расланган (2022 елның 5 апрелендәге 76од номерлы боерык редакциясендә)

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннар исемлеге

| № п/п | Муниципаль берәмлек исеме | Махсус билгеләнгән урын адресы | Махсус билгеләнгән урын тасвирламасы |
|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы | Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Мөслим, Пушкин ур., 92А йорт | “Яшьлек” универсаль спорт залы бинасы артында урнашкан автостоянка территориясе: Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Мөслим авылы, Пушкин ур., 92А йорт (55.297562 53.187597) |